ПЕЧӘН ӨСТЕ

Җәй башында әле мондый уңыш турында хыялланып та булмый иде

> 2

ЯРАТКАННЫ ЯРАТА

Нәселе яхшы булган атның киләчәге өметле

> 2

КАЙТЧЫ ИЛГӘ, СӨЕМБИКӘ

Ханбикәгә һәйкәл салу хыялы халкыбыз күңелендә күптәннән яши

> 3

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

Татарстан районнарында һәм авылларында Сабантуйлар гөрләде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 83 (28856) | Чәршәмбе | 15 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БӘЙРӘМЛЕ ХАЛЫК – БАЙ ХАЛЫК

Шушы гыйбарәгә тугрылык саклап, Татарстанда ел саен республикада яшәүче халыкларның милли бәйрәмнәре гөрләп уза. Быел кайда һәм ничек күңел ачарбыз? Бу хакта Хөкүмәт йортында узган брифингта сөйләштеләр.

Гадәттәгечә, күңел ачулар бөтен Татарстан буйлап узачак һәм җәй буена сузылачак. Инде рус халкының Каравон һәм мариларның Семык бәйрәмнәрен уздырып җибәрдек. Күпләр авыл Сабан туйларында да ял итәргә өлгергәндер. Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова әйтүенчә, халыкның үзенчәлеге аның бәйрәмнәрендә саклана. Бу үзенчәлекне күрергә һәм күрсәтергә кирәк. «Россия халыкларының мәдәни мирасы елы уңаеннан Татарстанда 80ләп этнографик фестиваль оештырырга ниятләгән идек. Бәйрәмнәрнең күбесен инде күңелле генә уздырып җибәрдек. Алда тагын бәйрәмнәр көтә», – диде ул.

Республикада милли бәйрәмнәрне уздыру дәрәҗәсе елдан-ел арта. Халыклар ассамблеясының башкарма комитеты рәисе Константин Яковлев шундый фикердә. «Мин моны Россиядә уза торган башка милли бәйрәмнәрдә бик күп йөргән кеше буларак әйтәм. Бездә республика җитәкчелегенең зур ярдәме сизелә. Моннан тыш, милли бәйрәмнәр этнотуризм үсешенә уңай йогынты ясый. Татарстанда яшәүче халыкларның көнкүреше, йолалары, гореф-гадәтләре белән танышу өчен генә дә күпме турист килә безгә!» – диде ул.

«Уйнап-көлеп, җырлап-биеп бәйрәм итик көн буе...» Без, гади халык, бәйрәмнәрне шушы җырдагычарак уздырсак, аларны оештыручылар ел буе тырыша. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров шулай ди. «Мин моны Сабан туе мисалында раслый алам. Әйтик, быел милли бәйрәмебез дөньяның татарлар яши торган 35 илендә һәм Россиянең 58 төбәгендә уздырыла. 400гә якын Сабан туе дигән сүз бу.

Татарстанда яшәүче халыкларның милли бәйрәмнәре

18–19 июнь – Казан Сабан туе
25 июнь – Тәтеш районының Килдеш авылында мордва (мукшы) мәдәниятенең Валда шинясь бәйрәме
2 июль – Баулы районының Покровский-Урыстамак авылында удмурт мәдәниятенең Гырон быдтон бәйрәме
8 июль – Яшел Үзәндә славян мәдәниятенең Иван Купала бәйрәме
10 июль – Әлки районының Сиктерме-Хузангай авылында чуаш мәдәниятенең Уяв бәйрәме
16 июль – Мамадыш районының Җөри авылында керәшен мәдәниятенең Питрау бәйрәме
19 июль – Лениногорск районының Мордва Кармалкасы авылында мордва (эрзя) мәдәниятенең Балтай бәйрәме

Аларга әзерлек инде әллә кайчан башланды. Кабул итүче як белән бергә әзерләнәбез», – дип аңлатты ул. Форсаттан файдаланып, 17–18 июньдә Ульян өлкәсендә узачак федераль Сабан туена, 1–2 июльдә Мордовиянең Ләмберә районы Аксен авылында үтәчәк Бөтенроссия татар авыллары Сабан туена, 26 июньдә Кемерово өлкәсенең Новокузнецк шәһәрендә оештырылачак Халыкара Шахтерлар Сабан туена дәшеп калды.

Бәйрәмнәр уздыруның шактый чыгымлы эш булуы инде берәүгә дә сер түгел. Шул ук Сабантуйны алыйк. Бүген бит авылда уза торган бәйрәмнәргә дә җырчы-йолдызлар чакыру популярлашты. Моны исәпкә алмасаң да, оештыру, бүләкләр һәм башка чыгымнар бар. Шушыларны каплый алмаган җирлекләр дә юк түгел. Чит төбәкләрдә шәп итеп бәйрәм уздырабыз икән, Татарстанның үзендә мондый хәл булырга тиешме? Журналистларның әлеге соравына Данис Шакиров җавап бирде. «Читтә уза торган бәйрәм чыгымнарының күп өлеше – кабул итүче як өстендә. Без исә бәйрәмнәргә артистлар җибәрәбез, аларның юл чыгымнарын түлибез. Моннан тыш, Татарстан Президенты исеменнән федераль һәм бөтенроссия татар авыллары Сабан туе батырларына җиңел машина бирелә», – дип аңлатты ул.

Сабан туе – рәсми чара түгел, ул – халык бәйрәме. Элек аны уздыру өчен дәүләттән ярдәм көтүче булмаган. Ирада Әюпова әнә шулай ди. «Соңгы елларда Казанда Сабан туена бүләк җыю йоласы уза. Элеккедән калган матур күренеш бу. Ул чакта кешеләр, кем ничек булдыра ала, шулай ярдәм итеп, бәйрәмне үз көчләре белән уздырган. Һәркемнең өлеше кергәч, бәйрәм кадерлерәк, якынрак та булган».

Бүләк җыю, димәктән. 17 июнь 11.00 сәгатьтә Казанда махсус маршрут буенча Сабан туена сөлге җыю йоласы узачак. Бу хакта «Татар-информ»да үткән матбугат очрашуында сөйләделәр. Казан һәм Татарстанның ресторатор һәм отельерлар ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязов сүзләренчә, шәһәр халкы һәм җитәкчеләр бүләк җыюда елдан-ел активрак катнаша. «Бүләк җыючылар милли уен коралларында уйнап, милли җырлар башкарып, матур атларда башта Кремльгә керәчәк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бүләген тапшырачак», – диде ул.

Маршрутның икенче ноктасы – Опера һәм балет театры. Анда Хөкүмәт йортыннан, Бөтендөнья татар конгрессы, республика парламенты, Мәдәният министрлыгы, опера театрының үзеннән, Ирек мәйданындагы предприятиеләрдән бүләк җыю ниятләнә. Аннан «Туган авылым» комплексына юл тотачаклар. Бүләк җыюның соңгы ноктасы – Иске Татар бистәсе. Сөлге җыю Камал театры янындагы мәйданда концерт программасы белән тәмамланачак. Сабантуйга бүләген теләгән һәркем тапшыра ала.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

Киләсе елда ачыла

«Мәскәү – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын киләсе ел азагында ачу күздә тотыла. Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин әйтүенчә, 2023 ел ахырына М12нең башкаладан Казанның урау юлына кадәрге өлеше әзер булачак һәм аның аша машиналар йөри башлаячак. Калган эшләрне – ярдәмче юллар, чистарту корылмалары төзү, трассаның тирә-юнен төзекләндерү-яшелләндерүне 2024 елда хәл итү планлаштырыла.

Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, юл төзүгә һәр көн саен 17 мең кеше һәм 5 мең берәмлек техника җәлеп ителә. Ә өченче кварталда инде анда 31 мең кеше эшләячәк һәм 9 мең берәмлек техника кирәк булачак. Вице-премьер аңлатып үткәнчә, юл төзү бәясе 800 миллиард сумнан күбрәккә кыйммәтләнгән. Төзелеш материаллары бәясе үсүгә һәм юлны Екатеринбургка кадәр озайтуга бәйле бу. Шул ук вакытта вице-премьер Татарстанда юл өчен Идел аша күпер төзүнең барышы белән танышкач, эшне тизрәк башкарып чыгу бурычын куйган.

Түләүле вузда түләмиләр

Яңа уку елында Татарстанда дәүләтнеке булмаган 3 вузга 217 бюджет урыны бирелә. Шулай итеп, ТИСБИ һәм Иннополис университетлары – 82шәр, Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты 53 бюджет урыны алачак.

2022/2023 уку елында Татарстанның барлык югары уку йортларында 20788 егет-кыз Россия һәм республика бюджетлары хисабына бушлай укыячак. Шуның 70 проценты республиканың 3 зур вузына – КФУ, Казан илкүләм тикшеренү-технологик университетына һәм КНИТУ-КАИга туры килә.

Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко белдергәнчә, вузларга керү кампаниясе 20 июньнән дә соңга калмыйча башланырга тиеш. «Быел мәктәпне тәмамлаучыларның 64 проценттан артыграгы бюджет урыннарына керә алачак. Сентябрь аеннан бу юнәлешләр буенча 245 мең чамасы егет-кыз белем эсти башлаячак», – дигән ул.

Ял итәргә – Казанга

Быел Казанга килүче туристлар саны пандемиягә кадәрге чор – 2019 ел күрсәткеченә җитәргә мөмкин. Ул чагында Татарстан башкаласында 3,5 миллион сәяхәтче булып киткән. Туризм буенча комитет директоры Дарья Санникова шулай дип белдергән. «Май бәйрәмнәрендә туристлар ташкыны 30 процентка артып, 200 мең кешегә җитте. Казанга ял көннәрендә генә түгел, гаиләләр, балалар белән иркенләп тә киләләр», – дигән ул.

Санникова әйтүенчә, бер килгән туристларда безгә кабат килеп чыгу теләген уяту бурычы тора. Хәзер Казанны сайлаган сәяхәтчеләрнең 60 проценты чамасы безгә кабат килә. Аларның өченче, дүртенче тапкыр килүләре күзәтелми.

Кимүгә барабыз

Быел дүрт ай эчендә Татарстанда 16444 кеше вафат булган. Әлеге күрсәткеч узган елның гыйнвар – апрель чорындагы (16925 үлем-китем очрагы) белән чагыштырганда 2,8 процентка кимегән. Апрельдә республикада 3427 үлем-китем очрагы теркәлгән. Бу – узган елның шушы ук айларындагыга караганда 11,9 процентка кимрәк.

Дүрт айда Татарстанда балалар да азрак (8,5 процентка) туган. Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, республикада шушы чорда 11706 (узган елда – 12795) нарасый дөньяга килгән.

Россия буенча күрсәткеч тә дүрт ай эчендә 6,2 процентка кимегән. Бу чорда барлыгы 420073 бала (узган елда – 447628) дөньяга аваз салган. Апрель аенда туучылар гомумән 9,9 процентка азайган.

Хәерле юл!

Рульне белеп тот

МАШИНА ХУҖАЛАРЫН ЕЛ ДӘВАМЫНДА ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТӘ

Машина йөртүчеләргә гел уяу булырга кирәк. Кагыйдәләр үзгәрешенә карата да. 2022 ел дәвамында «тимер ат»ияләренә нинди яңалыкларга әзер торырга? Шуларны барладык.

Соңрак түләү

Узган елның декабрендә Дәүләт Думасы яңа закон кабул итте. Аның нигезендә суд приставларына вазыйфаи затларның катнашыннан башка гына аларның бурычларын кайтарту мөмкинлеге бирелә. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен вакытында түләнмәгән штрафлар буенча бурычлар да автомат рәвештә алыначак.

ЮХИДИ идарәсе мәгълүматларына караганда, штрафларның 80 проценты 20 көн эчендә түләнелә. Билгеле булганча, «тимер ат» хуҗаларына бу аралыкта штраф күләменең яртысын гына кайтару мөмкинлеге бирелә. Көттереп кенә түләүчеләр дә җитәрлек. Андыйларны махсус рейдлар оештырып та тоткарлыйлар.

Мөмкинлекләре арта

29 июньнән керәчәк яңа закон нигезендә, банкта, иминиятләштерү компанияләрендә, элемтә операторларына, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларында паспорт урынына машина йөртү таныклыгын күрсәтергә мөмкинлек биреләчәк. Аны акча күчерү, иминият, банк, почта, мобиль хезмәтләрдән файдалану өчен күрсәтергә була.

Салмышларга кыенрак

29 июньдә «Корал турында»гы Федераль законга төзәтмәләр үз көченә керә. Аерым алганда, алар гражданнар

kzn.ru

коралын алуга лицензия биргәндә күбрәк чикләүләрне күздә тота. Әйтик, үзгәреш үз көченә кергәннән соң, кайчандыр салмыш килеш машина йөрткән яисә машинасын исерек хәлдәге кешегә биреп торган затларга ау өчен корал сатып алу турында онытырга туры киләчәк. Корал лицензиясен административ җәзага дучар ителгән сроктан бер ел узганнан соң гына яңадан алырга мөмкин булачак.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Төрле тармакларның үсеше өчен ачышлар ясаган дөньякүләм танылган галимнәребез үз заманнарының мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында белем алганнар. Аларның ачышларыннан без бүген дә файдаланабыз. Шуңа күрә һәр чорның иң яхшы якларын алып калырга кирәк.

(Россия Дәүләт Думасы пленар утырышында ясаган чыгышыннан)

РОССИЯНЕҢ КУНАКЧЫЛ ШӘҺӘРЛӘРЕ

«SuperJob» хезмәте белгечләре Россиянең иң кунакчыл шәһәрләрен барлаган. Сораштыруда катнашучыларга: «Үз шәһәрегездә туристлар саны артуын теләр идегезме?» дигән сорау биргәннәр.

Волгоград	60%
Красноярск	59%
Екатеринбург	59%
Самара	58%
Казан	53%

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 6–16 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 423 сум 48 тиен, гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 942 сум 18 тиен, гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТАГЫН КРИПТОТҮНТӘРЕЛЕШ

Җир шарында тотрыксызлык спирале үткән атнада яңа зур бер бөтерелеш ясады. Яшәешнең барлык тармаклары – финанс базарлары, геосәясәт өлкәсе, дәүләтләрнең эчке тормышы зур иләктә иләнүне хәтерләтә. Миллиардлаган кешеләр кичә генә өмет баглаган валюталар бүген чүпкә чыга, илләр белән илләр маңгайга маңгай килеп чәкәләшергә торалар…

Тынычлык проблемаларын тикшерү буенча Стокгольм институты атом-төш коралын куллану куркынычының салкын сугыш елларыннан соң үзенең иң югары ноктасына җитүен белдерде. Атом-төш державалары арасында конфликтлар үсә, зур армияләр тоткан дәүләтләр бер-берсенә яный. Урта диңгез, Кара диңгез, Фарсы култыгы, Тын океан төбәкләрендә вазгыять аеруча куркыныч. Кытай – Тайван конфликты, Кытай – Һиндстан каршылыгы, Пакьстан – Һиндстан традицион дошманлыгы аз гына да кимеми. Исламабад: «Кытайга каршы сугыш башланса, Пакьстанга каршы башланган сугыш дип кабул итәчәкбез», – дип белдерде. Төрекләр, Гыйрактагы хәрби операцияне төгәлләп, Сүриянең төньягында зур чистарту башларга җыена. Сүз Россия контролендәге төбәк турында бара. Әле ярый Әнкара белән Мәскәү бу мәсьәләдә уртак тел таптылар. Эгей диңгезендәге утраулар тирәсендә көтмәгәндә төрек – грек конфликты кискенләште. Килешү нигезендә греклар кулындагы ул утрауларда корал булмаска тиеш, әмма Афина соңгы вакытларда төрекләрнең борын төбенә корал китерә. Әрдоган «Твиттер»да бу уңайдан, Грециягә бик нык янап, пост элде.

Әлеге конфликтларның нигезендә финанс тотрыксызлыгы ята. Акча базарлары яна-дөрли, илләр икътисадлары мәтәлчек ата. Газета хәбәрчесе, бу юллар әзерләнгәндә, Мәскәү вакыты белән иртәнге сәгать 5.44тә: «S&P 500 индексы 2021 елның гыйнварыннан соң иң түбәндә ябылды һәм рәсми рәвештә «аю базары»на керде», – дигән хәбәр алды. «Аю базары» дип финансчылар телендә акцияләр кисәк 20 процент һәм аннан да түбәнгәрәк очсызланганда әйтәләр. Бу дәвамлы түбәнәю вәгъдә итә һәм инвесторлар триллионлаган акча югалта. Аю һөҗүм итсә, корбанын өзгәләп бетерә, биржа түнтәрелешенең исеме шуннан алынган.

Криптовалюталар базары акцияләргә караганда да кискенрәк түбәнәя. Без дүшәмбедә ял иткәндә, Көнбатышның криптовалюта базарларында чын мәгънәсендә фаҗига уйналды. Башта «Биткоин 10 процентка түбәнәйде» дигән хәбәр, аннан соң «Соңгы җиде көндә түнтәрелеш 20 процентка җитте, биткоин хәзер 24 мең доллар тора, S&P 500 һәм Nasdaq индекслары, криптоакчалар белән кулга-кул тотынышып, түбәнгә оча» дигән яңалык килеп иреште. «Биткоин 21 мең доллардан да түбәнәйсә, иң күп биткоиннарны үз кулында тотучы Microstrategy маржин колл хәлендә калачак. Бу биткоинның 15 мең доллар һәм аннан да түбәнгәрәк китәчәген вәгъдә итә», – дип яздылар. Сишәмбе иртәсенең 6 сәгать 57 минутында телефонда «Биткоин – $21800. Миллиардлаган долларлык маржин колл өзелүгә чүп кенә ара калды» дигән хәбәр яктырды. АКШта компьютерга биткоин дигән ялган сан язу өчен майнингка 25 процент энергия тотыла. Россиядә – 2 процент. Майнингка бездә тотылган энергия авыл хуҗалыгы тотканга караганда күбрәк. Нобель премиясе лауреаты Пол Кругман криптовалюталарның берничи дә кыйммәте булмавын, мошенниклар һәм караклар өчен генә хезмәт итүен гел искәртеп килә. Компьютерга бер тиенгә дә тормаган цифр язып кую өчен күпме энергия тотылуын карагыз да энергетик кризисның ни өчен килеп чыгуы турында фикерләгез. Боларның барысы да бит безне бөтендөнья сугышына якынайта.

Россиядә

СУМ НЫГЫЙ: ШАТЛАНЫРГАМЫ, ЕЛАРГАМЫ?

Россия акчасы тотрыклылык буенча мастер-класс кына күрсәтеп калмый, рекордлы рәвештә ныгуын дәвам итә. Менә карагыз: АКШның фонд базары 3 көндә 10 триллион долларга якын капитал югалткан, глобаль базарның югалтуы – 16 триллион. Криптовалюталарга акча тыгучылар 2 триллион доллардан колак каккан. Алтын һәм металлар түбәнәя. Япония банкы иенаның 1998 елдан соңгы рекордлы очсызлануын хәбәр итә. Бер янки долларына хәзер 135 япон иенасын бирәләр. Һинд рупиясе тарихта беренче тапкыр бер долларга 78ле курс белән сатыла башлады. Евро, йомшарып, доллар белән тигезләште диярлек. Спекулянтлар: «Ышанычлы бер актив та калмады», – дип үксиләр. Бары тик рус сумы – рубль генә, бөтен валюталарга үч итеп, гадәттән тыш ныклык һәм катылык үрнәге күрсәтә. Доллар бәясе 57 сумга да тулмый, евро да шул тирәдә генә бәяләнә.

Сумның болай ныгуы финанс хакимиятләрен дә, экспортка товар сатучыларны да һәм, гомумән, ил җитәкчелеген дә хәвефкә салды. Экспортерлар инде, сумны йомшартуны сорап, хөкүмәткә ультиматум куя башладылар, чөнки милли валютаның ныгуы аларны бөлдерә. Үзәк банк та, Президент администрациясе дә, федераль хөкүмәт тә доллар белән бил алышканда, сумның өскә чыгуына бер дә шатланмыйлар. Үзәк банк үткән җомгада төп ставканы 9,5 процентка кадәр төшереп, долларга ярдәмгә ашыкты. Ставка төшү банк депозитларының процентын түбәнәйтә, халык акчасын депозиттан алып, валюта базарына китерә, янәсе.

Депозитлар, чынлап та, саега башлады, диделәр. Бу кәгазь акчага сорауны арттыра. Әмма доллар сатып алырга теләүчеләр күбәю сизелми. Кәгазь доллар һәм евро алу – хәтта рәсми курстан күпкә югарырак бәягә дә, мөшкел эш. Банкларда кәгазь валюта кытлыгы, сата алмыйлар. Бу базар бик кечкенә. Акчаны банклар хисабындагы электрон долларга алыштыру – шулай ук хәвефле эш. Берничә банк валюта кертемнәренә тискәре процентлар керттеләр инде. Минус унике процент таләп итүчеләр бар. Ул банкка валюта кертеме ясасаң, бер ел эчендә мең долларның йөз егермесен үз файдасына каерып ала. Башына тай типмәгән кеше күрәләтә торып үзен талатмый инде. Чит илләргә хәзер бер айга 150 мең долларга кадәр акча чыгарып була. Бу да аз ярдәм итә. Гади халыкның чит ил банкларында хисап ачу мөмкинлеге юк диярлек. Россия банкы хисабындагы доллар кәнфит кәгазе бәясенә дә тормый, чөнки чит илләр аңа берни дә сатмыйлар диярлек. Шундый вазгыятьтә Путин валюта базарын либеральләштерә торган яңа карар кабул итте. Экспортерларга хәзер валютаның илле процентын сату таләбе бетерелде. Бу долларны өскә күтәрерме, юкмы – әйтү кыен. Салым түләү өчен барыбер валютаны күпләп сатарга туры киләчәк, диләр. Ә менә алырга теләүчеләр бик юк. Импорт өчен бик яхшы вазгыять бу. Дөрес булса, май импорты апрель белән чагыштырганда ике тапкыр арткан, диләр. Бу базарларда бәя төшүе булып кайтаваз бирсен иде һич югы. Әмма Үзәк банк долларның очсызлануы да инфляциягә китерәчәк дип куркыта.

ЧӘЧӘК АТ, ИЛЕМ!

ТАТАРСТАН РОССИЯ КӨНЕН ЗУРЛАП БӘЙРӘМ ИТТЕ

Илнең иң төп бәйрәме. Татарстанда һәм башкалада 12 июнь – Россия көнен зурлап билгеләп үттеләр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзенең тәбрикләмәсендә: «Ышанам ки, Россия көнен бәйрәм итү кешеләр бердәмлегенең ачык мисалы булачак һәм үз көчебезгә ышаныч бирәчәк», – дигән иде.

Башка бәйрәм котлауларында да бердәмлек, татулык сүзләре еш телгә алынды. Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева да «Казан» гаилә үзәгендәге сәхнәдәге чыгышында шул төшенчәләрнең әһәмиятенә басым ясады.

– Иң авыр вакытларда Татарстан халкы, Россия халкы һәрвакыт кыюлык, сабырлык үрнәге булуын күрсәтте. Чын күңелдән Россия көне белән котлыйм. Мин Россия Коралды Көчләренә көч, батырлык, кыюлык телим! – дип мөрәҗәгать итте ул.

Сүз уңаеннан, бу көнне Ләйлә Фазлыева укуда һәм иҗтимагый тормышта уңышка ирешкән яшь казанлыларга паспорт тапшырды.

Көч дигәннән, бу көнне Яшел Үзәндәге Горький исемендәге заводта тарихи вакыйга булды. Биредә ике фәнни-тикшерену судносы корпусларына нигез салынды. Алар дөнья океаны һәм шельф зонасын океанографик тикшеренүләр өчен хезмәт итәчәк.

Республиканың вице-премьеры Рөстәм Нигъмәтуллин белдергәнчә, заводта корабларны төзүдә иң яхшы белгечләр катнаша. Завод хезмәткәрләре башкарылган эшнең сыйфаты республика өчен генә түгел, ә бөтен Россия суднолар төзелешенә дә йогынты ясавын аңлый, дип билгеләп үтте ул.

kzn.ru

Казанның «Җиңү паркы»нда исә «Бердәм Россия» партиясенең «Яшь гвардия» бүлекчәсенең төбәк активистлары катнашында акция узды.

– «Za Россию!» патриотик акциясе кысасында Россия әләме төсендә тасмалар таратабыз, тематик фотосессия, махсус уеннар оештырабыз, – дип сөйләде «Яшь гвардия» бүлекчәсе активисты Андрей Киселев.

Бәйрәм икәнен күккә карап та белергә мөмкин иде. Парашютчылар бу көнне күккә 14 метрлы Россия әләмен күтәрде. Акцияне Россия ДОСААФ оешмасының Татарстан буенча Үзәк аэроклубы Илкүләм халык фронты командасы белән берлектә әзерләде.

Кич исә «Казан» гаилә үзәге гөрләде. Башкала халкын һәм бәйрәм кунакларын Россиянең һәм Татарстанның танылган җырчылары катнашындагы концерт җыйды. Россия көне салют белән тәмамланды.

Рульне белеп тот

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Махсус яшермә!

1 сентябрьдән түләүле автомобиль юллары буйлап йөрүгә бәйле кагыйдәләр үз көченә керә. «Ирекле агым» системасы ярдәмендә түләүле трассада киртәләрсез генә хәрәкәт итү мөмкинлеге бирелә. Шлагбаумнарда туктап торасы юк, димәк. Закон нигезендә, түләүле участокта хәрәкәт иткән машинаны камера теркәгәннән соң, «тимер ат» хуҗасының счетыннан юл хакы алыначак. Акча юк икән, бурычны мөстәкыйль рәвештә түләү өчен автомобиль хуҗасына биш тәүлек вакыт бирелә. Шуңа да трассага пычрак номер белән керү тыела. Номерны махсус рәвештә яшереп, үзгәртү дә дөрес гамәл түгел.

Укылмый торган номер өчен штраф күләме – 500 сум. Тик шофер махсус рәвештә машина номерын нәрсә белән дә булса капласа, нидер ябыштырса яки башка хәйләләр ярдәмендә аны яшерергә маташса, ул чакта штраф биш мең сумга кадәр җитәчәк. Моңа өстәп өч айга машина йөртү хокукыннан мәхрүм итәргә дә мөмкиннәр.

ЯРАТКАННЫ ЯРАТА

Республикада Сабантуйлар гөрли. Кыр һәм көрәш батырлары белән бергә милли бәйрәмнең төп күрке – атлар турында Мөслимдәге «Аргамак» ат спорты мәктәбенә баргач сөйләштек.

Хәйриячеләр ярдәме белән төзелгән спорт мәктәбе 2018 елдан бирле эшли. Шуннан бирле аны Фазаел Вәлиев җитәкли. Хәер, мәктәп ачу идеясе дә – 25 ел гомерен атлар белән бәйләгән, ат өстендә йөрү буенча өченче категориягә ия спортчыныкы.

– Ул вакытта мин Игенче авылында атлар тота идем. Элеккеге район башлыгы Рамил Муллин белән аралашканда: «Әйдәгез, Мөслимдә ат мәктәбе төзик әле», – дип мөрәҗәгать иттем. 2016 елның көзендә төзелеш башланды. Тора-бара үземдәге атларны бирегә алып килдем. Бераздан ул, балалар өйрәнсен дип, атлар алырга акча табып бирде. Бәхеткә, хәзерге җитәкчебез Альберт Хуҗин да атларны ярата. Ярдәм кирәк түгелме дип, сорап-белешеп кенә тора, – ди Фазаел Вәлиев.

Хәзерге вакытта биредә 16 ат тәрбияләнә. Аларның җидесе юртак һәм чабышкылар булса, калганнарында балалар йөри. Биредә 10 яшьтән алып 17 бала бушлай шөгыльләнә. Тренер ярдәме белән атларны каршылык аша сикерергә дә өйрәтәләр.

– Халык атлар белән кызыксына. Колхоз-совхозлар булмагач, авылларда атлар юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә әлеге малга сусаганнар безгә килә, – ди Фазаел абый. – Элек ат иярләмәгән егетләр бик сирәк була торган иде. Сабантуйга чабышкы әзерләгән ир-егетләргә сокланып үстек. Шөкер, әле дә өмет бар. Мәктәпкә йөрүчеләр арасында атны шулкадәр яраткан, алар белән кызыксынган, киләчәкләрен шушы спорт белән бәйләргә теләүчеләрне күреп, күңел сөенә. Бик теләп йөрүчеләрнең нәтиҗәләре дә бар. Гомумән, балаларның һәркайсы үзенә беркетелгән атны ярата. Әгәр башка баланы утыртсаң, үпкәлиләр, елыйлар.

Атлар да сынатмый. Спорт ярышларында ирешелгән уңышлары да бар. Даими рәвештә катнашып киләләр. Әле менә быел да берничә Сабантуйга әзерләнәләр. Узган ел Бөтенроссия Сабан туенда Россиядә туган атлар арасында – беренче, Татарстанда туган атлар арасында икенче урын алганнар.

– Зур, көчле ипподром атлары белән ярышабыз без, – ди горурланып Фазаел абый. – Бу – шулай ук тырышлык, тәҗрибә, тәрбияләү, атларны дөрес сайлау нәтиҗәсе. Бер атыбыз ике яшендә Россия буенча – бер, Татарстан буенча ике рекорд куйды. Аны Мәскәүгә алып киттеләр. Быел нинди нәтиҗә күрсәтер икән, дип дулкынланып көтеп торабыз. Бик җитез бер пониебыз да бар. Бер укучыбыз аның белән ярышларга йөри. Сынатмый. Балаларга күңелле булсын, белеп торсыннар дип, бер ишәк тә тотабыз.

Ат спорты мәктәбендәге атларның иң кыйммәтлесен 350 мең сумга сатып алганнар. Биредә татар токымлы ике ат та тәрбияләнә. Фазаел абый атларны бик ярата. Атларның төсле төшләр күрүен дә, сәгатенә 60 км тизлек белән чабуын да, басып йоклауларын да, ас белән өсне бертигез дәрәҗәдә күрү сәләте турында да аерым бер рәхәтлек белән сөйләде ул. Аның әйтүенчә, ат хуҗасы белән үзләре генә белгән телдә аралаша, бигрәк тә күз карашыннан бер-берсен аңлыйлар икән. Атлар күз, борын, колак, ияк тирәсендә урнашкан төкләре ярдәмендә сизә. Тик нинди генә көчле булса да, бал кортларыннан курка, ди. Ә менә Сабантуйлар алдыннан атларга игътибар тагын да көчәя.

– Без аларга һәрвакыт туклыклы, сыйфатлы ризык бирәбез. Бу вакытта атларның холыклары үзгәрә. Көчле күнекмәләр ясый башлагач, ат үзен ярышка әзерләүләрен сизә. Кызып китүчән, ярсучан холыклыга әйләнә. Күңеле белән мәйданга ашкына башлый. Бу вакытта ашауларына кадәр үзгәрә. Ял итә-итә, салмак кына ашаган атларга тизлек өстәлә. 4 яшеннән ат үзенең артта яки алда килүенә үз мөнәсәбәтен белдерә

Илдар Мөхәммәтҗанов

башлый. Артта калса, холыксызлана, борчыла. Алдан килсә, шатлана инде, билгеле. Кешеләр дә шулай бит. Кайбер атлар кызу канлы була. Алары ашыга, – ди ат белгече.

Фазаел абый әйтүенчә, атның җитезлеге табигатьтән бирелә.

– Аларның кайсы ун яшькә кадәр яхшы йөри. Кайсы инде сигез-тугыз яшьтә үк карьерасын тәмамларга мөмкин, – ди ул. – Шулай да күпчелек чабышкылар өчен иң көчле, гайрәтле, җитез вакыт – 4–6 яшь. Нәселе яхшы булган атның киләчәге өметле. Йөртүчесеннән дә күп нәрсә тора, әлбәттә. Атны сиземләү кирәк. Ә күнекмәләр ясаган вакытта аның холкын өйрәнеп бетәсең инде. Ул синең иң якын дустыңа әйләнә. Ә тугры дусны яратмау мөмкин түгел.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ХАЛЫК АШЫГА – ТӨШӘ БАСУГА

Быелгы гадәти булмаган яз кырдагыларны шактый хафага салды: күп эшләр соңга калды. Кайбер елларда безнең Балтач районы хуҗалыклары май азагында печәнгә төшә иде. Ә быел күпьеллык үлән басулары тап-такыр диярлек торды. Әмма табигатьнең көче гаҗәеп: алдагы көннәрдә булган җылы яңгырлар үлән-печәннәрне колагыннан тартып үстергәндәй үстерде. Шулай итеп, елдагы вакытка – Сабантуйга печән басулары өлгереп тә җитте.

Әле бәйрәмнәр үтмичә, печәнгә керешеп булмас дигән сала халкы да печән җирләрен күреп, тел шартлатты: быелгы печән гади чалгы, мотočалгы белән җиңел генә чабып алмаслык булып, каерылып уңган. Кайбер басуларда әле гади чапкычлы тракторларның гына да көче җитәрлек түгел, роторлы чапкычлардан башка ерып чыгам димә. Соңгы көчле яңгырлар аларның бер өлешен егып та чабучыларга зур уңайсызлык тудыра.

Өлгер хуҗалар көннәрнең шактый салкынча торуына да карамастан, Сабантуйга кадәр үк печәннәрен чабып куйган булса, кояш көткәннәр бәйрәм көннәрендә өй янындагы бакчаларында чалгыларын (читтәге басуларны тракторлар чаба) эшкә җикте. Алдан чапканнар да тик тормый, печән әйләндерә, ялларның соңгы көнендә инде рулонлатып алып кайтучылар да булды. Халык ашыга, чөнки интернетта кояшлы көннәр берничә генә күренә, өстәвенә мәгълүмат та үзгәреп тора. Авыл халкы өчен печәннәрнең кибеп, коры килеш керүе бик мөһим шул. Ә менә күмәк хуҗалыкларда мондый проблема юк.

Күптән түгел Балтач районында үткән республикакүләм «Сенаж көне»ндә – терлек азыгы әзерләүгә багышланган семинарда районнарга 20 июньгә терлек азыгы культураларының беренче

Илдар Мөхәммәтҗанов

кат уңышын җыйнап алу бурычы куелды. Үләннәрне чәчәк атар алдыннан чабып алганда, печән составында файдалы матдәләр күбрәк була, соңга калып җыйганда алар 40–50 процентка кадәр кими, ди белгечләр. Шуңа күрә авыл хуҗалыгы системасында эшләүчеләрне, күләме дә кирәк дип, печәннең калынайганын көтәбез дип, сыйфат мәсьәләсен икенче планга калдырырга ярамый дип, кат-кат кисәттеләр. Республиканың төньягында урнашкан районнар Сабантуйларга кадәр үк печән әзерләргә керешсә, төньяк районнарга 13 июньнән калмый бу эшкә алынырга тәкъдим иттеләр.

– Бездә дә берничә хуҗалык бәйрәмнәргә кадәр үк эш башлады, калганнар сишәмбедән терлек азыгы әзерләргә керешге, – ди Балтач районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш белгече Ирек Галимов. – Соңгы елларда бездә терлек азыгы культураларының мәйданнары шактый артты, азык әзерләүгә зур игътибар бирелә. Техникалар паркыда яңартылды. Күбрәк «Макдон», «Полесье», «Ягуар» комбайннары, инде ун еллап җидешәр-тугызар метрлы заманча чапкычлар кулланыла. Мондый чапкычлар булмаган хуҗалыклар хәзерге көндә юк та. Һәркайсында – икешәр-өчәр комбайн. Шулай ук заманча әйләндергечләр, тараткыч, җыйгычлар… – барысы да җитәрлек. Шөкер, кадрлар белән дә проблема юк.

Гадәттә район хуҗалыклары беренче кат уңышның күпчелеген (һава торышына карап) коры печән, ягъни рулонлаутөргәкләү ысулы белән әзерли. Шул ук вакытта траншеяга сенажга, төргәкле сенажга да алалар. Соңгысын бер ияләшкән хуҗалыклар ел да күп итеп әзерли. «Бик күп яктан үзен аклый. Сыйфатлы да, сакларга уңайлы да булуы өстенә, яңгырлы һава торышында да чаптырылган үләннәрне ике-өч көннән җыйнап алып була», – диләр. Беренче кат печәннән, елдагыча, хуҗалыкта эшләүчеләргә дә «процент печәне» өләшергә ниятлиләр.

Илдә булса, кырда үссә, күмәк хуҗалык малына да, шәхси малларга да өлеш мулдан чыга. Ә кырлар күпне вәгъдә итә. Җәй башында әле мондый уңыш турында хыялланып та булмый иде. Исән-имин җыйнап алырга язсын.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КАЗАН ҺАМАН СИНЕ КӨТӘ, СӨЕМБИКӘ!

10 июнь көнне Ока елгасы буенда урнашкан борынгы калаларыбызның берсендә, Рязань өлкәсендәге Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачылды.

dumrt.ru

Тантанада катнашкан һәр чыгыш ясаучы, аерым алганда, Рязань өлкәсе хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Анна Рослякова, Татарстан Хөкүмәте Рәисе урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы башлыгы Равил хәзрәт Гайнетдин, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты, федераль татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Илдар Гыйльметдинов бу мәрасимне тарихи вакыйга дип бәяләде.

Күңел түрендәге хыял

Сер түгел, Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл салу хыялы халкыбыз күңелендә бик күптәннән яши. Казахстанда яшәүче атаклы рәссамыбыз Камил Мулдашевның Ханбикә сыны проектын ясап, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка тәкъдим итүе, берничә ел элек Бөтендөнья татар конгрессы оештыра торган татар дин әһелләре җыенында Президентыбызның бу һәйкәлне куярга вәгъдә бирүе дә шуны дәлилли. Мәгълүм ки, узган гасырның туксанынчы елларында бу тәкъдим төрле-төрле мөнбәрләрдән кат-кат яңгыраган иде. Ни өчен әлеге идея һаман Казанда тормышка ашырылмый дисезме? Күрәсең, әле һаман сәгате сукмаган. Күрәсең, әлеге һәйкәл әүвәл Касыйм җирендә торып басарга (һәйкәлнең авторы Вениамин Сидоренко. **– Ред.**) тиеш булган. Мәгълүм ки: 1551 елны тотык итеп Мәскәүгә озатылган Казан ханбикәсе, бер ел чамасы рус дәүләте башкаласында мәҗбүри тотылганнан соң, Касыйм ханы Шаһгалигә кияүгә бирелә. Ханбикә христиан дине кабул итмәгәч, улы Үтәмешгәрәй әнисеннән тартып алынып чукындырыла, православ итеп тәрбияләнә. Александр исеме бирелгән ханзадә язмышы да әнисенеке кебек фаҗигале: ул 18 яшендә вафат була, Мәскәү Кремлендәге чиркәүләрнең берсендә җирләнә.

Әле бит шунысы да бар: Сөембикә җәсәденең Касыйм шәһәренең кайсы төшендә җирләнгәне бүгенгәчә төгаен мәгълүм түгел (үзен яратмаганын даими сиздереп торганы өчен, Шаһгали Сөембикәгә: «Халык кабереңнең кайда икәнлеген дә белмәс», – дип әйткән, диелә борынгы риваятьләрдә). Дөрес, узган җомга көнне Касыйм шәһәренең Хан мәчетендә уздырылган җомга намазында мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин, мәчет янәшәсендә урнашкан төрбәдә, ике хан кабере янәшәсендә исемсез тагын бер кабер бар, ул, һичшиксез, Сөембикә җәсәде булырга тиеш, дип белдерде. Хәер, бу фаразны милләтпәрвәрләребез күптәннән әйтеп килә.

Башкалабыз Казанда Сөембикәгә һәйкәл салу – безнең күптәнге хыялыбыз ул. Казан ханлыгына нигез салучы Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәткә түгел, нәкъ менә Сөембикәгә һәйкәл салу идеясе күңелебезгә ни өчен шулкадәр якын соң? Чөнки ханбикәбезнең язмышы татар халкы язмышы кебек фаҗигале, четерекле. Гомумән, халыклар мифларга ышанып яши, диләр. Халкыбыз арасында киң таралган «Сөембикә» бәетендә ханбикәбез, илбасарларга бирелмәс өчен, манарадан җиргә ташланган, дип әйтелә. Дәүләтчелеген, бәйсезлеген югалтуны халкыбыз менә шушылай бик зур фаҗига, олы хәсрәт дип кабул иткән. Халкыбыз арасында Сөембикә исеменең бик популяр булуы, сабыйларга әле дә күпләп шушы исемнең бирелүе, ханбикәбезгә багышлап әдәби әсәрләр, җырлар иҗат ителүе шушы хакта сөйли. Төгаен алганда, шагыйрь Разил Вәлиевнең «Сөембикә» шигыренә композитор Резедә Әхиярова язган җыр (сүз уңаеннан, шагыйрьнең кызы да Сөембикә исемле) һәйкәл ачу тантанасында да, шул көнне кичен Касыйм шәһәре мәдәният йортында уздырылган зур концертта да, алдагы көнне, ягъни 9 июньдә шушы вакыйга уңаеннан Касыйм шәһәрендә оештырылган фәнни-гамәли конференциядә – алтынчы Мөхлисә Буби укуларында да яңгырады.

Ай елмая зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә!
Язмышыңа хуҗа булып,
Кайтчы илгә, Сөембикә!

Бу шигъри юлларда халкыбызның өмете, хыялы бик тулы чагыла. Шуны раслап, Татарстан Хөкүмәте Рәисе урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев һәйкәл ачу тантанасында: «Бу – Сөембикә-ханбикәбезгә куелган беренче һәйкәл, әле аның икенчесе, өченчесе дә... булачак!» – дип белдерде.

Илкүләм вакыйга бу

Тантана тәмамланганнан соң Сөембикә шәхесен, һәйкәл ачылу вакыйгасын ничек бәялисез, дип, бик күп шәхесләребездән сораштык. Мәскәү шәһәре татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Фәрит Фарисов: «Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының беренче рәисе Индус Таһиров Сөембикәгә һәйкәл салу идеясен зур мөнбәрдән 1995 елда ук халыкка җиткергән иде. Ниһаять, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте тырышлыгы белән әлеге идея тормышка ашты, бу гамәлнең төп чыгымнарын безнең нәзарәт үз өстенә алды», – дип сөйләде. Үз чиратында Индус ага: «Сөембикәне Казанда да, Касыймда да бик яратканнар. Сөембикә тарихы ул – безнең уртак тарих, Россия тарихы. Татар факторы – Россиянең бөтенлеге шарты. Россия чәчәк атучы, демократик дәүләт булырга тиеш. Илебезнең киләчәге аның халыкларының ихтыярында», – дип белдерде.

Сөембикәгә кайбер шәхесләребез кырын карый, нигә шулай икән, дигәч, тарихчы Нурулла Гариф: «Һәркем үзеннән чыгып бәя бирә. Сөембикә шәхесеннән тискәре сыйфатлар эзләгәннәр аны тискәре итеп күрә, уңай ягын эзләгәннәр аны уңай образ, дәүләт эшлеклесе итеп бәяли. Ул үз-үзенә хуҗа булмаган, һәрвакыт дәүләт мәнфәгатьләре алга чыккан. Шәхескә тарихи күзлектән чыгып бәһа бирергә кирәк», – дип сөйләде.

Себердән, Тубылдан килгән тарих фәннәре кандидаты Зәйтүнә Тычинских, Сөембикәнең язмышын соңгы Себер ханы Күчемнең хәләл җефете, Сүзге-ханбикә язмышы белән чагыштырды. Себер татарларының Тубыл җирендә дә Сүзге-ханбикәгә һәйкәл салырга җыенуларын хәбәр итте.

Күренекле тарихчыбыз Дамир Исхаков ханбикәбезне зур дәүләт эшлеклесе һәм аянычлы язмышлы татар хатын-кызы буларак бәяләде. Мәскәүдә яшәүче, татар морзалары дәвамчысы Рәис Яушев, һәйкәл ачылуны тарихи гаделлекнең торгызылуы дип бәяләде.

Рәшит МИНҺАҖ

ФАҖИГА СИСКӘНДЕРӘ

ТРАНСПОРТ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ТУРЫНДА СӨЙЛИ БАШЛАСАЛАР, КҮЗ АЛДЫМА МОННАН 45 ЕЛ ЭЛЕК БУЛГАН ВАКЫЙГА КИЛЕП БАСА

Хәтер

«Урак һәм чүкеч» заводы 1976 елда «Аккош» күле янында урнашкан «Ялкын» пионер лагеренда 125 еллыгын билгеләп үтте. Җиңүчеләрне котлау өчен бер елдан уңайлы теплоходта сәяхәт оештырырга карар кылдылар.

Авторның шәхси архивыннан

«Грузия» теплоходын пристаньга таба этеп баралар.

Сентябрь аенда Чаллыга барасы булдык. Яңа шәһәр урамнарында йөрисе, даны илгә тарала башлаган куәтле КамАЗ берләшмәсе белән якыннан танышасы, үзебезнең заводта ясалган конвейерларның гамәлдә ничек эшләвен үз күзләребез белән бик тә күрәсе килә иде.

Шулай итеп, социалистик ярышка нәтиҗә ясалды, җиңүчеләр билгеләнде. Чаллыга баручылар исемлегендә 130га якын кеше бар иде. Кайберәүләргә хатыннарын, ирләрен, балаларын да алырга рөхсәт иттеләр. 25 сентябрь көнне әбәттән соң өчләр тирәсендә Елга портына җыела башладык. Ике сәгатьтән Идел буйлап түбәнгә таба кузгалып киттек. Каюталарга кереп урнаштык. Сәяхәт бик күңелле башланып китте. Күңел ачу чаралары да үткәрелде. Рәхәтләнеп ял иттек. Төн уртасында гына йокларга яттык. Иртәнге икеләр тирәсендә көчле бәрелүдән кинәт уянып киттем. Бераздан бу хәл янә кабатланды. Юлдашым Харис та уянды, тәмәке тартырга чыкмакчы булды. Аяк киемен эзли башлады, тапмады. Утны кабызып җибәрде һәм без... өнсез калдык. Аяк киемнәре, носкилар суда йөзеп йөри. Теплоход уң якка янтая башлады. Тиз генә киемнәребезне алдык та, баскыч буйлап, югары палубага күтәрелдек. Кешеләр уяна башлады. Теплоход янтаюын дәвам итте. Бөтен дөнья караңгылыкта, әйләнә-тирәбездә су, ут сүнде, двигательнең тавышы ишетелми башлады. Без бата башладык. Йөрәкләрне тетрәндереп, SOS сиренасы яңгырады. Елау, кычкыру, сүгенү тавышлары арта барды. Халык паникага бирелде.

Килеп чыккан хәлгә дөрес юнәлеш бирү өчен тиз генә штаб оештырылды. Балаларны, хатын-кызларны, өлкән яшьтәгеләрне югары палубага урнаштырдык. Теплоход командасы якында булган йөзү җайланмаларын ярдәмгә чакыра башлады. Атабайда Иделнең икенче ярына автомобильләр чыгару белән шөгыльләнгән паром ярдәмгә килде. Ул килеп җиткәндә, яктыра башлаган иде инде. Без ярдан – 1–1,5 чакрым ераклыкта. Көннәр салкын тора иде ул вакытта, су да бик салкын. Паром, бик оста гына маневр ясап, безне елганың тирәнрәк урынына чыгарды. Батып баручы бортны канаты белән эләктереп, Чистай шәһәренә юл тотты. Юл уңаенда безгә тагын бер кечкенә паром килеп кушылды. Ул да бортның икенче ягыннан трослар белән тарттырып барды. Чистай шәһәренең причалына килеп туктаганда, төшке аш вакыты җитә иде инде. Безгә, сезне каршы алырлар, ашатырлар һәм җылы залга урнаштырырлар, диделәр. Халык, чыннан да, бик туңган һәм кайнар чәйгә мохтаҗ иде. Әмма...

Теплоходны паром белән бергә дебаркадерга куяр урынга, ни өчендер бер-берсеннән аерырга булдылар. Ычкындырып җибәрүләре булды, янә бата башладык. Зур кыенлык белән теплоходны, кыегайган хәлдә, буксир ярдәмендә причалга бәйләп куйдылар. Безгә ботка һәм кайнар чәй тәкъдим иттеләр. Аларны егыла-егыла үзебез таратып йөрдек. Пристаньда бик салкын иде. Шуңа туристларның күбесе теплоходта калды. Алар инде хәлдән тайган, нык арыган иде. Күңел әрнеде. Менә сиңа ял иттек, дөнья күрдек...

Күпмедер вакыт узды. Икенче теплоходның килүе турында хәбәр иттеләр. Монысын бушатырга куштылар. Буксирга алып, икенче урынга бәйләп куйдылар. Елга порты хезмәткәрләре белән сөйләшкәндә, алар: «Күлмәк киеп тугансыз», – диделәр. Әгәр паром вакытында килеп җитмәсә, без, һичшиксез, су төбенә киткән булыр идек. Соңыннан ул тишекләрне күрдем мин: уң яктагы төптә ике урында «корсагы ертылган» иде.

Ниһаять, өч палубалы «Белоруссия» теплоходы килеп туктады. Җитәкчебез килеп чыккан хәл өчен гафу үтенде һәм, Чаллыга сәяхәтебезне дәвам итә алабыз, дип белдерде. Ләкин бөтенесе беравыздан өйгә кайтасы килүләрен әйттеләр. Шулай итеп, без Казанга юл алдык. Каршы алучылар аз иде. Чөнки ул чагында кәрәзле телефоннар юк иде бит. Кайтуыбызны белмәделәр. Өемә кайтып керү белән кызым Чулпанны кочаклап алдым. Ничек аны алып бармаганмын дип куандым.

Ни өчен чак кына фаҗига китерми калган шундый хәл килеп чыкты соң? Бу сорауны үземә кайта-кайта бирәм. Минемчә, сәбәбе берничә.

Беренчедән, капитан хатасы. Төнлә штурвалда тәҗрибәсе аз булган яшь судно йөртүченең үзен генә калдырган. Штурвалда, рулевой белән бергә, хәрәкәт юнәлешен һәм йөзү фарватерын билгеләүче штурман торырга тиеш. Икенчедән, сигнал калкавычының, маякларның тиешле күләмдә булмавы, маршрут картасына үзгәрешләр кертелүе турында оператив мәгълүматның җитешмәве. Ә ул кирәк, чөнки 1952–1956 елларда Куйбышев сусаклагычын су белән тутырганда фарватерларны һәм су басып китә торган зоналарның барысын да чистартырга өлгермәделәр. Ул 6450 квадрат чакрым мәйданны били. Халык яшәгән 149 авыл, 12 меңгә якын йорт, корылма, зиратлар, чәчүлек кырлары һәм урманнар су астында калды. Су астында калган урманнарны вакытында кисмәделәр. Агачларның кәүсәләре тырпаеп тора. Халыкта андый агачларны «корыч шәм»нәр дип атыйлар. Безнең теплоход нәкъ менә шундый «шәм»гә юлыкты. Өченчедән, суга баткан суднолар, йөк төягән баржалар, саллар, көймәләр, йөзеп йөргән бүрәнәләр дә зур куркыныч тудыра.

Татарстан Экология министрлыгы хисабыннан күренгәнчә, экологлар шуңа бәйле 99 суга бату очрагын теркәгәннәр. Алар быел җәйге чорда елга төбеннән 77 төр әйбер күтәрергә ниятлиләр. Минемчә, бу экологлар эше генә түгел, ә бәлки, баткан йөзү җайланмаларының хуҗалары эше дә... Кешеләрне, йөкне дә кирәгеннән артык төямәскә кирәк. Давыл вакытында һәм яннан көчле җил искәндә йөзү кагыйдәсен белмәү – минемчә, соңыннан «Булгария» дип йөртелә башлаган «Украина» теплоходының (2011 елның 11 июлендә 13 сәгать 30 минутта) су төбенә китүендә төп сәбәпләрнең берсе булды. Бу вакыйгага инде 11 ел вакыт узып китте, анда 122 кешенең гомере өзелде. Әлеге фаҗига дә без аздан гына батмый калган урыннан ерак түгел иде. Без аны әле бүгенгәчә онытa алмыйбыз. Искә төшкән саен һәр ике фаҗига дә сискәндереп куя.

Гарәфетдин ХИСАМЕТДИНОВ.
Казан

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Бер тамырдан – 700 тармак

Алар 10 ел саен гаилә бәйрәме уздыра. Бар нәселен бергә җыеп, Сабантуй ясыйлар. Тамырлары еракларга киткән үзләренең. Кемерово шәһәре, Оренбург өлкәсендә генә түгел, Кореяда да яши икән туганнары. Ахунҗан бабай нәселе белән «Без тарихта эзлебез» дигән бәйгедә таныштык.

Үз гаиләләре хакында шулкадәр яратып сөйләүләре күңелгә үтеп кергән иде. Алар яныннан тиз генә үтеп тә китеп булмый. Әбиләренең 135 ел элек киеп йөргән күлмәгенең әлегә кадәр матур саклануына, киленнәренең 102 ел элек бирнә салып алып килгән сандыгына сокланмаган кеше калмады.

– Нәселебезнең 16 буынын ачыкладык. Бәйгедән соң тагын биш буыныбыз табылды. Без хәзер бик күбәйдек. Моннан 10 ел элек 485 кеше булсак, хәзер 700гә җиттек. Моның өчен архивларда утырырга, авылдагы өлкәннәрдән сорашырга, сандык төпләреннән эзләнергә туры килде, – ди Ахунҗановлар нәселен дәвам итүче Райлә Галәвина. – Бабайның бишенче буын оныгы мин. Бабабыз 1868 елда Олы Шыңар авылында туа. Ул сәүдәгәр була. Хатыны Бибифатыйха белән иген игеп, мал асрап көн күргәннәр, 10 бала тәрбияләп үстергәннәр. Бабамны 1930 елда, кулак дип, сөргенгә җибәрәләр. Ул шушы газаплардан Магнитогорск якларында үлеп кала. Хатыны, бабай үлгәч, кире Сабага кайта. Әмма сагыну үзенеке итә, ирем янәшәсендәрәк булыйм дип, кире китә.

Нәселләрендәге иң өлкән 98 яшьлек Әминә апалары май аенда вафат булган. Шушы көннәрдә нәселләрен дәвам итеп, Лилия һәм Рузил Ахунҗановларның балалары туган.

Нәселне барлый башлагач, Ахунҗан бабай оныклары кадерле ядкәрләргә дә тап була. Сандык төпләреннән ни генә чыкмый?! Тамгалы эш кораллары да, сыер өчен түләгән салым, иминият кәгазьләре дә табыла.

– Ахунҗан бабайның Фәйзрахман исемле улы сугышта катнаша. Аңа исән-сау, орден-медальләр белән кайтырга насыйп була. Ул Сталинның 9 рәхмәт хатына лаек була, – ди Райлә. – Эзләнә торгач, нәсел тамгабыз да табылды. Уч төбебез нинди – ул шундый. Аның аңлатмасын уйлап, үзара сөйләшәбез, бәхәсләшәбез. Шушы тамга белән без нәселнең кан белән, җан белән тартылган өзелмәс чылбыр булуын исбат иттек.

Ахунҗан бабай оныклары көн саен аралашып тора. Моның өчен «Ватсап»та төркем булдырганнар. Шунда 130 туган рәхәтләнеп сөйләшә икән. Ахунҗан бабай нәселен бер учка җыеп торучы кешеләрен дә белдек. 4 нче буын оныгы Ришат Ахунҗанов барысын да бергә җыя, очрашулар оештыра.

Ахунҗановлар нәселе республика күләмендә уздырылган «Без тарихта эзлебез» бәйгесендә беренче урынга лаек булды. Бәйгедә җиңү яңа очрашуларга сәбәп була. Быел шул хөрмәткә Ахунҗан бабай оныклары Сабантуй уздыра.

– Беләсезме, бу бәйгедән соң күңелдә әйтеп бетерә алмаслык рәхәт хис барлыкка килде. Туган белән туган аралашмыйча яшәгән заманда без, киресенчә, тагын да якынайдык. Нәрсә генә булса да, бергәләп киңәшәбез, бер-беребезгә ярдәм кулы сузабыз. Тормышның мәгънәсе үзгәрде. Яшәү яме артты. Күңелгә горурлык кереп оялады. Мактану түгел ул, нәселеңне җыя алганга шатлану, – ди Райлә. – Әби-бабаларыбыз рухы шаттыр дип уйлыйм. Мондый чаралар еш үткәрелсен иде. Балаларга кечкенәдән туганнары турында сөйләп, алар арасын җылытып яшәсәк иде. Иң авыр чакта туганың кул суза. Әнә шуны онытмыйк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ
барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара
ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.
Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.
Пенсионерларга 15-20% ташлама!
Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.
Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!
тел.: 8 905 199 99 79
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

САБАНТУЙ КАЙТАВАЗЫ

КАЙСЫ РАЙОНДА КЕМ БАТЫР КАЛДЫ?

«ВТ» район үзәкләрендә узган Сабантуйларда батыр калган егетләрнең исемлеген барлады.

Азнакай – **Руслан Сәлимов**
Актаныш – **Фарис Хуҗин**
Аксубай – **Илсур Сафин**
Алабуга – **Илнар Галимов**
Алексеевск – **Андрон Абдуллин**
Апас – **Рафаэль Хәсәнов**
Арча – **Фаяз Зарипов**
Әгерҗе – **Денис Әминов**
Әлки – **Илназ Хәбибуллин**
Әлмәт – **Рамил Синәкәев**
Әтнә – **Руслан Абдуллин**
Балтач – **Руслан Рәфыйков**
Балык Бистәсе – **Айзат Зарипов**
Баулы – **Илмир Сабиров**
Биектау – **Раил Нургалиев**
Буа – **Марат Миначев**
Бөгелмә – **Аскар Сафин**
Зәй – **Руслан Хәмидуллин**
Кайбыч – **Владимир Токсаров**
Кама Тамагы – **Лениз Абдуллин**
Кукмара – **Ринат Дәүләтшин**
Лаеш – **Руслан Газизуллин**
Лениногорск – **Рөстәм Юсыпов**
Мамадыш – **Максим Степанов**
Менделеевск – **Роман Волков**
Минзәлә – **Рөстәм Бәдретдинов**
Нурлат – **Марсель Гозәеров**
Питрәч – **Андрей Чиндин**
Саба – **Радик Сафин**
Сарман – **Алмаз Миңнехуҗин**
Спас – **Ришат Сәгыйров**
Тәтеш – **Илназ Шәмсетдинов**
Теләче – **Раил Мараков**
Тукай – **Эльдар Хәмитов**
Түбән Кама – **Наил Зәйнуллин**
Чирмешән – **Марат Кәримов**
Чистай – **Булат Мусин**
Чүпрәле – **Рамил Айзатуллов**
Югары Ослан – **Руслан Һадиев**
Ютазы – **Хәмит Миңнуллин**
Яңа Чишмә – **Самат Әхмәтҗанов**
Яшел Үзән – **Фирдүс Зәйнуллин**

Арча

Быел район Сабан туеның «бисмилласы», ягъни кереш өлеше бик үзенчәлекле булды. Үзәк мәйданда энә төртерлек урын юк иде, дисәм дә, әллә ни арттыру булмас. Район мәдәният идарәсе башлыгы Илфар Әюпов әйтүенчә, 695 кеше чыккан иде мәйдан уртасына. Болар – мәктәпкәчә яшьтәгеләрдән башлап урта яшьләргә кадәр булган җырчылар, биючеләр, музыкантлар, нәфис сүз осталары, кыскасы, Арча талантлары. Кыска гына тамаша аша татар тарихы да, милләтләр дуслыгы да, бүгенге тормышыбыз да тагын бер кат җанланды. Иң әһәмиятлесе: тамашаның сценарий авторлары, хормейстер, балетмейстерлары да Арчаның үзенеке.

Без – мәйданга кунак итеп чакырылган язучылар, сәнгать әһелләре – Сабантуйның «таҗ»ы булган әлеге тамашага бер үк бәя бирдек, Арча талантлары чыгышы белән республика күләмендә уза торган теләсә нинди бәйрәмне башлап җибәреп була икән, дип мактаныштык. Һәм бу коры мактану түгел иде. Ни генә уйласак та, ни генә сөйләсәк тә, Болгар чоры, Казан ханлыгы чоры мәдәнияте-сәнгатенең Казан артына, Арча якларына күчүе хак, күрәсең. Мәйданда чорлар аша буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыкны бүген дә саклап килүчеләрне күрдек без.

Моннан 5–6 ел элек бер язучы үзләренең район җитәкчелегеннән зарланган иде. Баксаң, аны Сабантуйга кунак итеп чакырмый башлаганнар. Ә мин аңа: «Туган якка чакырып кайтмыйлар», – дип җавап биргән идем. Матур сүз өчен генә әйтмәдем мин бу сүзләрне. Туган як – туган як инде ул, без анда кунак түгел. Без анда – хуҗа. Ә хуҗа кеше туган як кайгысы белән кайгырып, шатлыгы белән шатланып яшәргә тиеш. Әни бер булган кебек, туган як та бердәнбер була. Һәрхәлдә, үзем шулай уйлыйм. Ярый әле Сабан туйларыбыз бар, бәйрәм-йолаларын саклап кала алган халык бар һәм ул яшәячәк, дим. Аларны саклау исә – һәрберебезнең бурычы, дим. Шуңа күрә туган якларга да кунак булып кына кайтмыйбыз.

Арча мәйданы бик матур урында уза. Тамашачы урыннары – түбә астында, шуңа күрә ара-тирә яугалаган яңгыр да, җил дә бәйрәм кәефен боза алмый. Мәйданның бер ягында – Казансу елгасы, ә тау башындагы каладан мәйданга төшәр өчен махсус юллар, сукмаклар эшләнгән. Ерактан караганда халык агымы тау елгалары ташкынын хәтерләтә.

«Яшәсен Сабантуйлар, яшәсен газиз туган ягым!» – дип кычкырасы килеп китә.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Минзәлә

Татарстандагы дәүләт театрлары артистлары бер мәйданда 18 июньдә очрашачак. Очрашачак та, милли көрәш, гер күтәрү, капчык киеп сикерү, чүлмәк вату, капчык сугышы һәм башка ярышларда көч сынашачак. Сәбәбе – XIV Театраль Сабантуй. Быел ул Минзәлә шәһәренең Урман чишмәсе янындагы мәйданда узачак. Бәйрәмгә теләгән һәркем чакырулы. Оештыручылар «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында аның быелгы үзенчәлекләре турында сөйләде.

Тинчурин театры җитәкчесе Фәнис Мөсәгыйтов сүзләренчә, бәйрәмнең нәкъ менә Минзәләдә узуының сәбәпләре берничә. «Данлыклы татар театры булган җирлектә Театраль Сабантуй булмыйча кала алмый. Минзәлә театры безне күптән үзләренә чакыра, бәйрәмне уздырырга атлыгып торалар. Минзәлә халкы да бик көтә бу чараны», – диде ул.

Быел Театраль Сабантуй программасында үзгәрешләр дә бар. Башка елларны көрәшкә артистларга гына керергә рөхсәт бирелсә, быелдан театр коллективында эшләгән һәр хезмәткәр бил алыша алачак. Абсолют батыр мәйданнан тәкә белән кайтып китәчәк. Башка еллардан аермалы буларак, быел төп бүләк – машина Сабан туе батырына түгел, ә ярышларда иң күп балл җыйган театрга биреләчәк.

Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә театры җитәкчесе Илнур Гайниев, беренче эш итеп, Сабан туе узачак мәйданны мактады. «Ык һәм Минзәлә елгасы буенда урнашкан бик матур мәйданчыгыбыз бар. Аның белән чын мәгънәсендә мактана алабыз. Бу мәйданчыкта һәр театр үз ишегалдын булдырып, бәйрәм кунакларын каршы алачак», – дип сөйләде ул.

Минзәлә районы башкарма комитетының яшьләр һәм спорт бүлеге җитәкчесе Фаяз Хизбуллин исә ярышларга кагылышлы ниятләре турында сөйләде. «Минзәләлеләр «мөгез чыгарырга» тиеш бит инде. Күпчелек уеннарның тәртибе үзгәрешсез калса да, берничәсен су өстендә уздырып, артистларны бераз чылатып алырга уйлыйбыз», – диде ул.

Сүз уңаеннан, Театраль Сабантуйның узган елгысында Минзәлә һәм Буа театрларына тиңнәр булмаган иде. 14 уенда призлы урын алды алар. Абсолют батыр исеменә дә Минзәлә театры артисты Нәфис Гайнуллин ия булды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

aznakayevo.tatarstan.ru

Мамадыш

Ул көнне кояш та җылысын кызганмады. Әйтерсең, ул да барысын да белеп тора. Районда кыр эшләре тәмамланган, инде күңел ачсаң да була. Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов та әнә шулай ди. Сабантуйга кайткан якташларга район алдынгыларын, уңганнарын, кул осталарын гына күрсәтеп калмый алар, һәркайсы хакында горурланып сөйли ул.

– Быел яз соңга калгач, бик борчылган идек. Шөкер, егетләребез эшне аяз көннәрдә тәмамлар өчен икешәр смена эшләде. Аларга рәхмәт әйтми, ни диярсең?! Сабан туе ул – авыл уңганнары бәйрәме. Шуңа да алар рәхәтләнеп ял итсен дип кулдан килгәнне эшләргә тырыштык, – ди Анатолий Иванов.

Быел Мамадыш Сабан туен оста оештырганнар. Мәйданга килгән һәркемгә лотерея билеты өләшәләр. Бәйрәм ахырында зур бүләкләр уйнаталар икән. Хәер, район Сабан туенда халык бик актив. Ел саен зур бүләкләр бирәләр дип, халык уеннарга чират тора. Кашыкка йомырка куеп йөгерү дисеңме, капчык киеп чабумы – уенда катнашкан һәр кешегә бүләк бирелә. Көчлеләр исә аркаларына салып йөгергән бер капчык оннарын үзләренә алып кайтып китә. Әмма уенның иң кызган урыны көянтә-чиләк белән йөгерү мәйданында иде. Олы яшьтәгеләр дә, яшьләр дә бу уенда бик теләп катнаша. Кызыл Тау бистәсендә яшәүче Йолдыз исемле кызга иптәш калмагач, мин уенга чыктым. Көчләр бертигез иде, икебезгә дә бертөсле бүләк эләкте.

Кемгә нәрсә инде, тамашачының күбесе Элвин Грей җырлаган сәхнә янәшәсендә иде. Үз районыбыз үзешчәннәре дә кимен куймады. Алар районда яшәүче һәр милләт вәкиленең көнкүрешен, гореф-гадәтен театраль тамашада күрсәтте. Татар, мари, удмурт, керәшен, рус көйләренә биемәгән кеше калмады. Кытайдан ук килгән кунак рәхәтләнде бәйрәмдә.

– Шаккатып утырам. Татарның милли ризыклары да тәмле. Җырлары да биетә. Мин Мамадышка ел да киләчәкмен, – ди Тун Цзюнье.

Бүләкләргә килгәндә, Сабантуйдан телевизорлы, микродулкынлы мичле, суыткычлы, мотоблоклы булып кайтып китүчеләр дә булды.

Түбән Яке

Быел халык кичке Сабантуйга җыелды. Кайткан кунаклар күп иде. Тау битләрендә сыйныфташлар очраша, мәйдан да гөрли.

Сабан туе авылдагы иң өлкән кешене хөрмәтләүдән башланды. Габделхак Муллаәхмәтовка 92 яшь икән.

Бәйрәм төрле уеннар белән үрелеп барды. Һава торышы көйсезләнеп китсә дә, уеннарда катнашучылар күп булды. Хәтта җырчылар үзләре дә чаңгы ярышында катнашты. Аларны күреп, безнекеләр дә активлашты. Миңа да бер уенда катнашырга насыйп булды. Мәйданга җибәрелгән әтәчне үзем тоттым. Кызык уеннар күп иде бәйрәмдә. Күзләрен бәйләп кадак каккан хатын-кызлар да, тау башына бүләккә дип йөгерүче ир-атлар да күп булды. Кыскасы, бәйрәм бик матур узды.

– Быелгы Сабантуй бер еллык көч бирде. Бәйрәм ясаганы өчен авылдашыбыз Рифат Мәхмүтовка мең рәхмәт! Гел игелекле эшләр башкара ул. Әле генә мәчет төзеттергән иде, инде менә җырчылар чакырып, авылдашларын ял иттерде. Мондый егетләр барда авыл яшәячәк, – ди Зәйдән кунакка кайткан Фәнзилә Таҗетдинова.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Бу атнада исә Сабантуйлар Чаллыда, Минзәләдә, Ульянда һәм Казанда узачак. Чаллыда милли бәйрәм 18 июньгә билгеләнгән. Шул ук көнне Минзәләдә – Театраль Сабантуй, ә Ульянда федераль бәйрәм булачак. Казанда 19 июньдә бәйрәм итәчәкләр.

Сабантуйлар алдагы атналарда да булачак. Әйтик, Мамадыш районындагы Югары Кыерлы авылында кунакларны 2 июльдә көтәләр. Биредә, һәрвакыттагыча, иң көчле көрәшчеләр җыела. Бил алышу ике үлчәү авырлыгында оештырыла. Беренче урынны алучыларга – 35000, икенче урынга – 25000, өченчегә 15000 сум акча вәгъдә итәләр. Баш батырга исә тәкә белән бергә квадроцикл да эләгәчәк.

Балтач

Ничә еллар инде район Сабан туенда (шулай ук авылларда да), район башлыгы фәрманы белән, спиртлы эчемлекләр сатылмый. Бәйрәмгә үзгә төсмер бирүче шәп карар бу. Аңа карап активлык та, катнашучылар саны да кимеми. Киресенчә, аек баштан да матур итеп бәйрәм итеп буласына үзләре дә инанды, килгән кунакларны да ышандыра килә оештыручылар.

Тагын бер үзгәлек: район Сабан туе «үз көнендә», ягъни күпчелек авыл бәйрәмнәреннән соң – якшәмбедә үтте. Электән килгән бер йоланы саклау кебек бу кадәресе. Мәйдан белән янәшәдә булган, соңгы елларда республика программасы буенча төзелгән «Сабантуй» ял паркындагы гүзәллек бәйрәмгә килүчеләрне, бердән, әсир итеп, бәйрәм рухын арттырса, икенчедән, гаиләләре белән ял итәргә теләүчеләргә өстәмә уңайлык та тудырган иде. Ел саен бәйрәмгә нинди дә булса үзгәреш, яңалык кертәләр бездә. Быел әнә районның барлык имамнарын мәйдан уртасына чакырып хөрмәтләделәр (Болгарда ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы хөрмәтенә). Алдынгыларга, сабан батырларына, районның мактаулы гражданнарына да хөрмәт зурдан булды.

Үткән ел район Сабан туенда бер җигүле ат чыгымлап, халык өстенә менеп, аздан гына бәйрәмнең ямен алмый калган иде (ярый әле азагы хәерле булды, беркем дә зыян күрмәде). Шуны сәбәп итеп, быел бизәкле атларны мәйданга кертмәскә кирәк, диючеләр дә булган. Әмма бизәкле, кыңгыраулы атлардан, тальян моңыннан башка бу бәйрәмнең бер чите китек булыр иде. Моннан да чыгу юлын тапканнар: быел милли киемнәр кигән егетләр бизәкле атларны йөгәненнән җитәкләп йөртте. Килешле дә булды, куркынычсызлык та тәэмин ителгән иде.

Төрледән-төрле уен-ярышлар, үзешчәннәр, профессиональ артистлар (былгы бәйрәмнәр аларның күплеге белән аерылып торды. Районныкында Айдар Галимов чыгыш ясады), кибетләр, уен-күңел ачу мәйданчыклары... – барлык бәйрәмнәрне бер-берсенә бәйли торган, шул ук вакытта һәркайсын кабатланмас та итә торган тамашачылар, катнашучылар – дүрт көн һәм кич буе «кайнады» район. Өч-дүрт Сабантуй карадык, дип мактанучылар бар. Ярышларда катнашып, саллы бүләкләр алучылар да, үзенең тәүге җиңүе белән куанучы батырлар да күп булгандыр.

Балтачта быел кемнең баш батыр каласын алдан фаразлаганнар ялгышмады. Яңгул пәһлеваны, күптән түгел билбау көрәшендә дөнья чемпионы калган Руслан Рәфыйков үткән елгы уңышын кабатлады.

Ә мин үзем күрше малае, быел бишенчене тәмамлаган Данияр өчен бик сөендем. Быел гына көрәш түгәрәгенә йөри башлаган Данияр беренче катнашкан авылыбыз Сабан туенда ук балалар арасында батыр калып, тәкә отты. Үзеннән ун килограммнан артык авырлыктагы яшүсмер белән бил алышып, аны җиңгән! Аның сыйныфташлары – апамның оныклары да үз авырлыкларында өченче, дүртенче урыннарда калганнар. Алар да кыйммәтле бүләкләргә бик сөенгән иде. Ә мин исә элек-электән көрәшчеләре белән данлыклы булган авылыбызда, ниһаять, ничә ел өзеклектән соң яңа буын көрәшчеләр үсә бит, дип куандым...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Буа

Шулай гадәтләнгән һәм күнегелгән инде! Яңа Тинчәледә халкыбызның милли бәйрәме ел да Коръән аятьләре укудан башлана. Илдар хәзрәтне тыңлаган саен тыңлыйсы гына килеп тора: гомумән, дини тәрбия, үгет-нәсыйхәтләре өчен авыл халкы аңа бик рәхмәтле. Аннан соң хезмәт алдынгыларын данлау – хөрмәтләү була, милли уеннарыбыз, көрәш эстрадабызның иң өметле яшьләре чыгышлары белән аралашып бара.

Яңа Тинчәле – 335 елдан артык тарихы булган, алдынгылары белән гомер-гомергә дан тоткан, республикабыз үсешенә гаять зур өлеш кертүче җитәкчеләр тәрбияләгән данлы-шөһрәтле авыл.

Буа районы башлыгы Ранис Камәретдинов та котлау сүзендә Яңа Тинчәле халкының максатчан, бердәм булуларына, туган төбәкләрен нык яратуларына, социаль мәсьәләләрне хәл иткәндә һәрвакыт җиң сызганып алынуларына, игелекле гамәлләр кылуларына басым ясады. Болар авылның төзеклегендә, өлкәннәрнең дә, яшьләрнең дә кәефендә, гомумән, бәйрәм барышында ачык чагыла иде.

Авылдашлары – Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ринат Рәүф улы һәм Татарстан финанс министры Радик Рәүф улы Гайзатуллиннар, Яшел Үзәндәге Серго исемендәге завод («Позис») генераль директоры Радик Хәсәнов, башка дәрәҗәле кунаклар: «Сабантуйлар – туган төбәк белән җанлы бәйләнеш ул», – дигән фикердә. Авылдашлар сөйләштеләр, серләштеләр, хәтер яңарттылар. Әле яңарак кына бакыйлыкка күчкән укытучылары, класс җитәкчеләре Миңнура Фәизованы юксынып, сагынып искә алдылар. Укучы балаларга ул, үз итеп, якын күреп: «Бәбкәм», – дип дәшә торган булган икән.

Радик Хәсәнов, Радик Гайзатуллин Сабантуйны оештыру чыгымнарын, һәр елдагыча, үз өсләренә ала. Көрәшчеләр исә «Позис» суыткычлары белән бүләкләнде, Радик Хәсәнов суыткычлар белән бергә авылдагы медпунктка медицина кирәк-яраклары да алып кайткан иде.

Шәхси эшмәкәр Фәнис Шәрәфетдинов мәйдандагыларга күптән инде күңелендә булып та, моңарчыга кадәр гамәлгә ашыра алмаган уй-теләген дә җиткерде.

– Хөрмәтле авылдашлар! Киләсе елда Сабантуй үткәрү чыгымнарын үз өстемә алачакмын, – диде ул. – Быел ук шундый ниятем бар иде, әмма Радик Рәүфович өлгеррәк булып чыкты. Киләсе елда миңа өметләнегез.

Менә шулай: изге гамәл башкаларны да игелеккә өнди.

Кыскасы, Сабантуй бик күңелле, эчтәлекле үтте.

– Минем өчен әлеге бәйрәм – әти-әни йортына – төп нигезебезгә тагын бер тапкыр кайту форсаты. Туганнар белән очрашу шатлыгы, Сабантуй башланганчы ук күңелләрне нечкәртеп, бәйрәмнең мәгънә-төсмерен тагын да киңәйтеп, баетып җибәрә, – диде филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Флера Сәйфуллина. – Авылыбызда Сабантуйның киң колач белән үткәрелүе, бер яктан, авылдашларыбызның тырыш хезмәт белән көн күрүен исбатласа, икенчедән, төрле өлкәләрдә абруй казанган якташларыбызның туган туфрагын онытмавы, ярдәмләшеп торуы, ел дәвамында бер тапкыр шушы сәбәп белән очрашу – хәл белешү, авылдашларны, сыйныфташларны барлау күңелдә эчке бер горурлык хисе уята, киләчәккә өмет баглана.

Фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Яңатинчәлеләргә хас уй-теләкләр, хис-кичерешләр бу.

Габделбәр РИЗВАНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 283

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+